ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**03.10.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№2755**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 08 декабрендәге 3393 номерлы карары белән расланган Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Зеленодольск муниципаль районы вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 08 декабрендәге «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 3393 номерлы карары белән расланган, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Зеленодольск муниципаль районы вазыйфаи затлары исемлегенә (21.02.2024 ел, № 488, 24.12.2024 ел, № 5372 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемлекне түбәндәге эчтәлекле 11.1 пункт белән тулыландырырга:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11.1 | **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының (КоАП РТ) 2.22 статьясы** | Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны чикләүне үтәмәү | - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге баш белгече;<br>-«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ башлыгы урынбасары;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ баш белгече;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ әйдәп баручы белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлеге баш белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече; |

1.2. Исемлеекне түбәндәге эчтәлекле 23.1 пункт белән тулыландырырга::

| | | | |
|---|---|---|---|
| 23.1 | **Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының (КоАП РТ) 3.19 статьясы** | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенә карата таләпләрне бозу | -Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ башлыгы урынбасары;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ баш белгече;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ әйдәп баручы белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлеге баш белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече. |

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин